КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 февраль г.Казань № 62

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кан донорлыгына булышлык күрсәтү турында» 2014 ел, 5 июнь, 379 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кан донорлыгына булышлык күрсәтү турында» 2014 ел, 5 июнь, 379 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 9 ноябрь, 855 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

алтынчы абзацта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Донор канын һәм (яисә) аның компонентларын әзерләү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләре тарафыннан гавами норматив йөкләмәләрне башкару һәм аларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең 5 пунктының бишенче абзацында «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – СТИБДМС)» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы» (алга таба – бердәм цифрлы платформа)» сүзләренә алмаштырырга, «СТИБДМС» сүзен «бердәм цифрлы платформа» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин